МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК_ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

2 4 03 2016

**Казан шәһәре**

49/2-пр

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, “Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында” Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында" Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә, б о е р а м:

1. Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары - министр

М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2016 елның 24 мартындагы № 49/2-пр боерыгы белән расланды

**Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турындагы нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, “Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында” Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында" Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә эшләнде.

Нигезләмә белән Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясен (алга таба - Комиссия) төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы түбәндәгеләрдә ярдәм итү:

а) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – Министрлык, дәүләт хезмәткәрләре) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу таләпләрен, чикләүләрне һәм тыюларны үтәүләрен, шулай ук алар тарафыннан "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларның (алга таба -

хезмәт тәртибенә куелган таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр) үтәлүен тәэмин итүдә;

б) Министрлыкта коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруда.

1.4. Комиссия Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын (алга таба - дәүләт хезмәте вазыйфаларын) биләүче дәүләт хезмәткәрләренә (вазыйфага билгеләп кую, аннан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәткәрләреннән тыш) карата куелган хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәүгә бәйле мәсьәләләрне карый.

1.5. Министрлыкта вазыйфага билгеләп кую, аннан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата куелган хезмәт тәртибенә таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрнең үтәлешенә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында оештырылган Хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе тарафыннан карала.

1.6. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

## 2. Комиссия составы

2.1. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана.

Комиссия составына Комиссиянең Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары арасыннан Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры (алга таба - министр) тарафыннан билгеләнеп куелучы Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре һәм әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары да карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) министрның беренче урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлыкның кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), кадрлар бүлегеннән, юридик бүлектән, Министрлыкның башка бүлекчәләреннән министр билгеләп куя торган дәүләт хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе һәм (яисә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәсе вәкиле;

в) эшчәнлекләре дәүләт хезмәтенә бәйле фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре).

2.3. Министр Комиссия составына Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет, Министрлыкның башлангыч һөнәр берлеге оешмасы һәм Министрлыкта төзелергә мөмкин булган ветераннар иҗтимагый оешмасы вәкилләрен кертү турында карар кабул итәргә мөмкин.

2.4. Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы "б" һәм "в" пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына министр үтенече буенча тиешле органнар һәм оешмалар белән килештерп кертелә. Килештерү үтенеч алынган көннән 10 көн эчендә башкарыла.

2.5. Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләмәүче Комиссия әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге булмаслык итеп төзелә.

2.7. Комиссия утырышларында түбәндәгеләр киңәш бирү тавышы хокукы белән катнаша:

а) үзенә карата хезмәт тәртибенә куелган таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрнең үтәлү мәсьәләсе Комиссия тарафыннан карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче, үзенә карата Комиссия тарафыннан әлеге мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре биләгән шундый ук вазыйфаларны биләп торучы һәм Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнүче ике дәүләт хезмәткәре**;**

б) Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча һәм комиссия тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә алырлык белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынучы оешмалар вәкилләре; Комиссия тарафыннан үзенә карата хезмәт тәртибенә куелган таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре вәкиле – Комиссия тарафыннан үзенә карата шул мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының үтенече нигезендә Комиссия утырышы көненә кадәр кимендә өч көннән дә соңга калмыйча һәр аерым очрак буенча кабул ителә торган Комиссия рәисе карары буенча**.**

2.8. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул хокуклы дип санала. Утырышларны Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.9. Комиссия әгъзасында Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки читләтеп шәхси кызыксыну барлыкка килгәндә, ул утырыш башланганчы бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта Комиссиянең бу әгъзасы әлеге мәсьәләне

карауда катнашмый.

## 3. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышын уздыру өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә үткәрелгән тикшерү йомгаклары буенча дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, хезмәт тәртибенә куела торган таләпләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан үтәлүен тикшерү буенча материалларны министр тарафыннан тапшыру, аларда түбәндәгеләр чагылдырылырга тиеш:

дәүләт хезмәткәрләренә дөрес булмаган яки тулы булмаган тәкъдим итү турында Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмә”дә каралган белешмәләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан дөрес булмавы яисә тулысынча бирелмәве турында;

хезмәт тәртибенә куелган таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан үтәлмәве турында;

б) кадрлар бүлегенә Министрлыкның норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә кергән:

Министрлыкта “Дәүләт хезмәткәре үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге”нә (Министрлык боерыгы белән расланган) кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көннән ике ел узганчы, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эшләүгә ризалык бирү турында мөрәҗәгате, әгәр әлеге оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса;

дәүләт хезмәткәренең үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне объектив сәбәпләр аркасында тапшыру мөмкинлеге булмау турында гаризасы;

“Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалата чараларны һәм башка кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен, территориясендә счетлары (кертемнәре) булган, акчалата чаралары һәм башка кыйммәтләре саклана торган, чит ил финанс инструментлары булган чит ил законнары нигезендә әлеге илнең компетентлы органнары тарафыннан арест салынуга, тыю билгеләнүгә бәйле, аның яисә хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган шартларга бәйле рәвештә, үтәү мөмкинлеге булмау турында дәүләт хезмәткәре гаризасы;

вазыйфаи бурычларны башкарганда, мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында дәүләт хезмәткәренә хәбәр итү;

в) министрның яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәүне тәэмин итүгә яисә Министрлыкта коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруга кагылышлы күрсәтмәсе;

г) министр тарафыннан “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләрне дәүләт хезмәткәренең дөрес яки тулы булмаган килеш тапшыруын таныклый торган тикшерү материалларын тапшыру;

д) “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясы нигезендә Министрлыкка коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмадан Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт һәм граждан-хокук шартнамәсе төзелү турында кергән хәбәрнамә, әгәр әлеге оешманың аерым дәүләт идарәсе функцияләре аның Министрлыкта биләгән вазыйфаи (хезмәт) вазыйфасына кергән булса һәм әлеге гражданга Комиссия тарафыннан элек бу оешма белән хезмәт һәм граждан-хокук мөнәсәбәтләренә керү рөхсәт ителмәгән яисә мондый гражданга коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында аңа эш башкаруга ризалык бирү мәсьәләсе Комиссия тарафыннан каралмаган булса.

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан кадрлар бүлегенә тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, яшәү урыны адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көнгә кадәр соңгы ике елда биләгән вазыйфалары, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешманың атамасы, урыны, аның эшчәнлек үзенчәлеге, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгәндә граждан тарафыннан башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) бурычлары, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмага карата дәүләт идарәсе функцияләре, шартнамә (хезмәт яисә граждан-хокук) төре, аның күздә тотылган гамәлдә булу срогы, эшләр (хезмәт күрсәтүләр) шартнамәсе буенча башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәт) өчен түләү суммасы. Мөрәҗәгать кадрлар бүлегендә карала, аның нәтиҗәләре буенча, “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

3.2.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән азат ителүне планлаштыручы дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылырга мөмкин һәм ул әлеге Нигезләмә нигезендә комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "д" пунктчасында күрсәтелгән

хәбәрнамә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан карала, ул Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законның 12 статьясы таләпләрен үтәве турында дәлилле бәяләмә әзерли.

3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан карала, ул хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә әзерли.

**3.4.2.** Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яисә әлеге Нигезләмәнең 6 пунктындагы бишенче абзацында һәм 3.1 пунктындагы "д" пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә әзерләгәндә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә биргән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә һәм аннан язма аңлатмалар алырга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен Министрлык дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрә ала. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән алып 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артыкка түгел.

3.5. Комиссия утырышы уздыру өчен нигез булган мәгълүматны Комиссия рәисе:

а) 10 көн эчендә комиссия утырышы датасын билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышы датасы, әлеге Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән 20 көннән дә соңга калмыйча билгеләнергә тиеш;

б) Комиссия үзенә карата хезмәт тәртибенә куелган таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләренең үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны кадрлар бүлегенә кергән мәгълүмат, шулай ук әлеге мәгълүматны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) Комиссия утырышына әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктындагы "б" пунктчасында күрсәтелгән затларны чакыру турындагы үтенечнамәләрне карый, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау (караудан баш тарту турында) турында карар кабул итә.

3.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында

мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срок чыкканнан соң бер айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "д" пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (план) утырышында карала.

3.8. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, үзенә карата хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре яисә Министрлыкта дәүләт граждан хезмәтен биләүче граждан катнашында үткәрелә, Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында дәүләт хезмәткәре яисә граждан әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда дәүләт хезмәткәре яисә граждан катнашыннан башка үткәрелергә мөмкин:

а) әгәр әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләге турында күрсәтмә булмаса;

б) әгәр Комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләге булган һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәр алган дәүләт хезмәткәре яисә граждан Комиссия утырышына килмәсә.

3.9. Комиссия утырышында Министрлыкта дәүләт хезмәткәренең яисә дәүләт хезмәтен биләгән гражданның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка чыгарылган мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар Комиссия эше барышында үзләренә мәгълүм булган белешмәләрне фаш итәргә хокуклы түгел.

3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "а" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр тапшыру хакында” 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрне дөрес һәм тулы, дип билгеләргә;

б) әлеге пунктның беренче абзацында аталган Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес түгел һәм (яисә) тулы түгел, дип билгеләргә. Мондый очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

3.12. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "а" пунктчасының өченче

абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәгән, дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәмәгән, дип билгеләргә. Мондый очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен бозмаска кушарга йә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

3.13. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада, әгәр бу оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирергә;

б) гражданга коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада, әгәр бу оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирүдән баш тартырга, һәм баш тартуны дәлилләргә.

3.14. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

3.14.

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр объектив һәм мөһим сәбәпләр аркасында бирелмәгән, дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрнең бирелмәве мөһим сәбәпләр аркасында түгел, дип танырга. Мондый очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә әлеге белешмәләрне бирү бирү буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирмәүнең сәбәбе объектив түгел һәм бу күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан читләшү ысулы булып тора, дип танырга. Мондый очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

3.15. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының

дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" Федераль закон таләпләрен үтәүгә каршылык тудыра торган шартларны объектив һәм аларны мөһим сәбәпләр дип танырга;

б) "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" Федераль закон таләпләрен үтәүгә каршылык тудыра торган шартлар объектив түгел һәм аларны мөһим сәбәпләр түгел дип танырга. Мондый очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

3.15.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан вазыйфаи бурычлар башкарылганда мәнфәгатьләр каршылыгы юк, дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан вазыйфаи бурычлар башкарылганда шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин, дип танырга. Мондый очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) министрга мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу яисә аның барлыкка килүен булдырмау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәмәгән, дип танырга. Мондый очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

3.16. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "г" пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге тиешле карар кабул итә.

3.17. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "г" пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә: а) "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы, дип танырга;

б) “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес түгел һәм (яисә) тулы түгел, дип танырга. Мондый очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә һәм (яки) чыгымнарны тикшереп тору нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки) башка дәүләт органнарына аларның компетенциясе нигезендә җибәрергә тәкъдим итә.

3.18. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "д" пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) граждан тарафыннан коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эш башкаруга, әгәр бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керә торган булса, рөхсәт бирергә;

б) гражданның хезмәт шартнамәсе шартларында коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләве һәм (яки) коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада эшләр башкаруы (хезмәтләр күрсәтүе) “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның 12 статьясы таләпләрен боза, дип билгеләргә. Мондый очракта Комиссия министрга әлеге хәлләр турында прокуратура органнарына һәм мәгълүмат биргән оешмага хәбәр итүне тәкъдим итә.

3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "а" - "д" пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, моңа нигезләр булган очракта, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17-3.18 пунктларында каралганнардан башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.20. Комиссия карарларын үтәү өчен министрның норматив хокукый актлары, карарлары һәм күрсәтмәләре проектлары әзерләнергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә министр каравына тапшырыла.

3.21. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр Комиссия башка карар кабул итмәсә) утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.22. Комиссия карарлары беркетмәләр итеп рәсмиләштерелә һәм алар Комиссия утырышында катнашкан Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карардан тыш, министр өчен тәкъдим итү характерына ия. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри характерда була.

3.23. Комиссия утырыш беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы датасы, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исеме;

б) Комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең формулировкасы, үзенә карата хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы;

в) дәүләт хезмәткәренә карата карата белдерелә торган дәгъвалар, аларны нигезләгән материаллар;

г) белдерелә торган дәгъваларның асылы буенча дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исеме һәм аларның чыгышларының кыскача бәян ителеше;

е) Комиссия утырышын уздыру өчен нигезләр булган мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның Министрлыкка керү датасы;

ж) башка белешмәләр;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

3.24. Комиссия карары белән килешмәгән Комиссия әгъзасы үз фиккерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул катгый рәвештә Комиссия утырышы беркетмәсенә беркетелә һәм аның белән дәүләт хезмәткәре дә таныштырылырга тиеш була.

3.25. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш көненнән соң 7 көн эчендә министрга, тулысынча яисә аннан өземтәләр рәвешендә дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары буенча башка кызыксынучы затларга җибәрелә.

3.26. Министр Комиссия утырышы беркетмәсен карарга тиеш һәм андагы тәкъдимнәрне, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның башка мәсьәләләре буенча карар кабул иткәндә, үз компетенциясе чикләрендә исәпкә алырга хокуклы. Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында министр үзенә Комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән бер ай эчендә Комиссиягә язмача хәбәр итә. Министр карары Комиссиянең якындагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышмыйча гына игътибарга алына.

3.27. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар җинаять билгеләре билгеләнгән очракта, бу хакта мәгълүмат министрга дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен тапшырыла.

3.28. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозуы яки җинаять составы билгеләре булган гамәлләр кылуы (гамәлләр кылмавы) факты ачыкланган очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәл кылу (гамәл кылмау) турындагы мәгълүматны һәм мондый фактны раслый торган документларны 3 көн эчендә, ә кирәк чакта - кичекмәстән, хокук куллану органнарына тапшырырга тиеш.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яисә аннан өземтә үзенә карата хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү турындагы мәсьәлә каралган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

3.30. Комиссия секретаренең имзасы һәм Министрлык мөһере белән таныкланган Комиссия карарыннан өземтә Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданга, Комиссиянең тиешле утырышы узган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, куй куйдырып

тапшырыла яисә аның тарафыннан күрсәтелгән адрес буенча хәбәрнамәле заказлы хат итеп җибәрелә.

3.31. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырышны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында Комиссия әгъзаларына мәгълүмат җиткерү, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышуга тәкъдим ителә торган материаллар белән таныштыру Кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.